КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З.Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен яңадан җиһазландыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 гыйнвар, 55 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З.Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен яңадан җиһазландыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 гыйнвар, 55 нче

карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июнь, 614 нче; 2023 ел, 18 июль, 855 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында» сүзләрен «Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен;»;

әлеге карар белән расланган Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазлауга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын яңадан җиһазландыру буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртиптә «Онкология авыруларына каршы көрәш» төбәк проектының онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын медицина әйберләре белән яңадан җиһазлау буенча гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмы билгеләнә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын медицина әйберләре белән яңадан җиһазлау буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү әлеге чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм федераль бюджеттан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – субсидия, бюджет акчасы) исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бюджет акчасы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган Россия Федерациясе Медицина ярдәме төрләре буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибендә, өлкәннәрне һәм балаларны

медицина тарафыннан реабилитацияләүне оештыру тәртипләрендә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган лаборатор, инструменталь, патологик-анатомик һәм диагностика тикшеренүләренең башка төрләрен уздыру кагыйдәләрендә каралган медицина оешмаларын (аларның структур бүлекчәләрен) җиһазлау стандартлары нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган медицина әйберләре исемлеге буенча медицина эшләнмәләре белән (медицина эшләнмәләренең технологик тасвирнамәләре эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең медицина эшләнмәләренә өстенлек бирергә тәкъдим итүне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен Яр Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендәге филиаллары белән яңадан җиһазлауга бирелә.»;

икенче абзацта «акча» сүзен «бюджет акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» сүзләрен «бюджет акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «Акча тоту» сүзләрен «Бюджет акчасын тоту» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар урнаштыра.

8 пунктта татар текстында «Акчадан» сүзен «Бюджет акчасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «акча» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З.Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен яңадан җиһазлауга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган Россия Федерациясе Медицина ярдәме төрләре буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибендә, өлкәннәрне һәм балаларны медицина тарафыннан реабилитацияләүне оештыру тәртипләрендә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган лаборатор, инструменталь, патологик-анатомик һәм диагностика тикшеренүләренең башка төрләрен уздыру кагыйдәләрендә каралган медицина оешмаларын (аларның структур бүлекчәләрен) җиһазлау стандартлары нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган медицина әйберләре

исемлеге буенча медицина эшләнмәләре белән (медицина эшләнмәләренең технологик тасвирнамәләре эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең медицина эшләнмәләренә өстенлек бирергә тәкъдим итүне исәпкә алып) яңадан җиһазлау өчен гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (алга таба – медицина оешмасы) субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – субсидия, медицина җиһазы) бирү күләмен һәм шартларын билгели.

Субсидия медицина оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын медицина әйберләре белән яңадан җиһазлау буенча Тчыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидия исәбеннән бирелә.»;

9 пунктта:

беренче абзацта «субсидия акчасы» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «субсидия акчасы» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «субсидия акчасы» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «субсидия акчасы» сүзләрен «субсидия» сүзенә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин